КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1032

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2024 елларда «Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 19 декабрь, 1366 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2024 елларда «Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 19. декабрь, 1366 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү турында»;

1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктта «2022 – 2024 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруны методик озата баруны тәэмин итәргә;

кирәк булганда Тәртипне куллану буенча аңлатмалар бирергә.»;

4 пунктта «пилот проектын гамәлгә ашыру» сүзләрен «психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда психик тайпылышлары булган

инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә акча бирүне күздә тотарга.»;

әлеге карар белән расланган 2022 - 2024 елларда психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибендә:

исемендә «2022 – 2024 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 пунктта «2022 - 2024 елларда «Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру кысаларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Әлеге Тәртип максатларында бергә яшәү дигәндә психик тайпылышлары булган, башка затлар ярдәменнән башка мөстәкыйль яшәү рәвеше алып барырга сәләтле булмаган инвалидларны өй шартларында яшәүне тәэмин итүгә, шулай ук мондый инвалидларның үз-үзенә хезмәт күрсәтү һәм төп тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерү сәләтен арттыруга (хезмәт һәм башка эшчәнлекне башкару, ял итү һәм аралашу) юнәлдерелгән чаралар комплексы аңлашыла.

Бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр инвалидларга алар яшәгән вакытта психик тайпылышлар булган инвалидларга торак бинада социаль хезмәтләр күрсәтүче тарафыннан арендага алынган социаль хезмәт күрсәтүдә төп тормыш ихтыяҗларын гамәлгә ашыруда максималь мөстәкыйльлек тәэмин итә торган күнекмәләр эшләү максатларында социаль хезмәтләр күрсәтүгә (көнкүреш продуктларын, кием-салым, дару чараларын сатып алу, азык-төлек әзерләү, кием-салым (стирка, глажка) һәм аяк киеме тәрбияләү, торак урынны җыештыру, ял итү, аралашу һәм социаль элемтәләрне) һәм мөстәкыйль тормышка җайлаштыру максатларында күрсәтелә.»;

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Психик тайпылышлары булган инвалидның бергә яшәүгә мохтаҗлыгы, аңа күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләме, вакыты һәм озынлыгын кертеп, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 91 статьясындагы дүртенче өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 28 июлендәге 606н номерлы боерыгы белән расланган инвалидның бергә яшәүгә мохтаҗлыгын билгеләү өчен кулланыла торган критерийларны исәпкә алып (организмның тереклек эшчәнлеге чикләүләрен һәм бозылган функцияләрен исәпкә алып) билгеләнә.

Психик тайпылышлары булган инвалидның бергә яшәүгә мохтаҗлыгын билгеләү өчен түбәндәгеләр исәпкә алына:

а) инвалидның бергә яшәүгә теләге булу, шул исәптән аны бирү формасында (индивидуаль яисә төркемдә);

б) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә һәм өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау;

в) инвалид тарафыннан өй шартларында тормыш урнаштыруны гамәлгә ашыру өчен кирәкле бурычларны һәм гамәлләрне башкарудагы кыенлыкларны һәм тормыш хәлләренә җәлеп иткәндә барлыкка килә торган проблемаларны бәяләү, тормышның төп категорияләренең чикләүләрен һәм инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль

программасында күрсәтелгән аларның тигезлек дәрәҗәсен исәпкә алып (алга таба - инвалид автономиясен бозу).

Психик тайпылышлары булган инвалидның автономиясен бозу дәрәҗәсен яңадан карау индивидуаль рәвештә башкарыла, ләкин кимендә өч елга бер тапкыр.

Психик тайпылышлары булган инвалидның бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүдә мохтаҗлыгын кабат билгеләү кимендә өч елга бер тапкыр индивидуаль рәвештә үткәрелә.»;

4.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«граждан бергә  яшәү буенча уку (тренировка) курсын узган социаль хезмәт күрсәтү оешмасы тарафыннан бирелгән автономияне бозу дәрәҗәсе күрсәтелгән килеш, бергә яшәү буенча уку (күнегүләр) курсын граждан тарафыннан уңышлы үзләштерү турында белешмә.»;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Гражданны бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау яисә тулы күләмдә тапшырмау тора.

Баш тартылган очракта психик тайпылышлары булган инвалид (аның законлы яисә вәкаләтле вәкиле) гражданны бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып 30 көн эчендә территориаль органга документларның тулы пакетын кабат тапшырырга хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.4 пункт өстәргә:

«4.4. Психик тайпылышлары булган инвалид (аның законлы яисә вәкаләтле вәкиле) территориаль органга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүне вакытыннан алда туктату турында язма яисә электрон формада гариза бирергә хокуклы.

Бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү бергә яшәүнең вакытыннан алда тәмамлануы турында гаризада күрсәтелгән датадан туктатыла.»;

6.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның һәркайсының автономиясе бозылу дәрәҗәсе;»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаның нумерация баш исемендә «2022 – 2024 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның нумерация баш исемендә «2022 – 2024 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаның нумерация баш исемендә «2022 – 2024 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин